Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Новотроицк авыл җирлегенең Шөгерчә авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

29 ноябрь 2019 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Шөгерчә авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссия сенең 2019 елның 29 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Шөгерчә авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Шөгерчә авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип таныrга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Новотроицк авыл җирлегенең Шөгерчә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 350 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Шөгерчә авылы юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу:торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныrга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Шөгерчә авылы, Үзәк урамы, 1а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Халык җыенында рәислек итүче
Новотроицк авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Лотфуллин